МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_______________ Казан шәһәре № ____________

Гражданнар өчен бюджет тәкъдим итү проектларының ачык гавами региональ конкурсын үткәрү турында

Гражданнар өчен җәмәгать финансы белән идарә итү турында ачык һәм файдалана алырлык мәгълүмат белән тәэмин итә торган форматта бюджет формалаштыруның иң яхшы практикасын ачыклау һәм тарату максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 маендагы 856-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Гражданнар өчен бюджет тәкъдим итү проектларының ачык гавами региональ конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәне расларга, кушымта итеп бирелә.

2. Бюджет сәясәте бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәлү өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
2016 елның
______ ______номерлы боерыгы
белән расланды

**Гражданнар өчен бюджет тәкъдим итү проектларының ачык гавами региональ конкурсын үткәрү турындагы нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнар өчен бюджет тәкъдим итү проектларының ачык гавами региональ конкурсын үткәрү турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2016 елда Гражданнар өчен бюджет тәкъдим итү проектларының ачык гавами региональ конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

Конкурс «Россия Федерациясе Хөкүмәте каршында финанс университеты» федераль дәүләт югары белем бирү бюджет учреждениесе тарафыннан үткәрелә торган Гражданнар өчен бюджет тәкъдим итү проектларының ачык гавами региональ конкурсы кысаларында уздырыла.

1.2. Конкурсның асылы Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бюджеты турында әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган аңлаешлы һәм файдалана алырлык мәгълүмат бирү проектын (алга таба – Конкурс проекты) эшләүдән гыйбарәт.

Конкурста катнашу өчен дәгъва итүчеләр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

бюджет проектын гражданнар өчен ачык һәм файдалана алырлык мәгълүмат белән тәэмин итә торган форматта бирергә;

тәкъдим ителгән проектны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр эшләргә.

Конкурс проекты конкурс тематикасы буенча актуаль тикшеренүдән торырга тиеш. Конкурс проектын эшләгәндә Конкурста катнашучылар түбәндәге таләпләргә таянырга тиеш:

Конкурс проектының эчтәлеге сайланган номинациягә (номинацияләргә) тәңгәл килергә;

номинациядә тикшерелә торган проблемалар буенча аларның актуальлеген, максатларын, бурычларын һәм нигезле дәлилләрен билгеләргә;

гамәли кулланылыш мөмкинлеге.

1.3. Конкурста физик затлар да, юридик затлар да катнаша ала. Бер Конкурс проекты берничә номинациядә катнашырга мөмкин, әмма катнашучы тиешле номинацияләрне күрсәтеп бары тик бер генә заявка бирә ала. Бер үк Конкурс проектын Конкурста бер үк вакытта физик һәм юридик зат исеменнән тәкъдим итүгә юл куелмый. Конкурс һәр номинациядә физик һәм юридик затлар арасында аерым үткәрелә.

1.4. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Бюджет: күпме түлим һәм күпме алам?»;

«Муниципаль берәмлек бюджеты: сораулар һәм җаваплар»;
«Гражданнар өчен интерактив бюджет»;
«Гражданнар өчен бюджетның аңлаешлылык рейтингын эшләү»;
«Бюджет терминнарының популяр сүзлеге»;
«Гражданнар өчен бюджетта социаль әһәмиятле проектлар»;
«Финанслау инициативасы проектлары».

1.5. Конкурста җиңүчеләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 маендагы 856-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә төзелгән конкурс комиссиясе (алга таба – Конкурс комиссиясе) билгели.

## II. Конкурс үткәрүне оештыру

2.1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы:

Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә гомуми җитәкчелек һәм контрольлек итә;

Конкурс үткәрелү турында игълан итә;

Конкурста катнашуга заявкалар кабул итә һәм аларның исәбен алып бара;

заявкаларның сакланышын тәэмин итә;

заявкаларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен ачыклый һәм Конкурста катнашу өчен заявкаларны алдан сайлап ала;

заявкалары әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килми торган дәгъва итүчеләргә Конкурста катнашуларын кире кагу турында хәбәр итә;

Конкурста җиңүчеләрне һәм катнашучыларны бүләкләүне оештыра.

2.2. Конкурс комиссиясе:

Конкурста катнашучыларның Конкурс проектларын бәяли;

Конкурс проектларының җыелма бәясен булдыра һәм раслый;

Конкурста җиңүчеләр турында беркетмә раслый.

2.3. Конкурс үткәрелү турында игълан 2016 елның 20 июненнән соңга калмыйча Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла һәм ул түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

заявкаларны кабул итү адресы (аралашу телефонының номерын һәм башка кирәкле белешмәләрне күрсәтеп), заявкаларны кабул итә башлау һәм тәмамлау датасы;

заявкага таләпләр, Конкурс проектларын бәяләү критерийлары.

2.4. Конкурста катнашуга дәгъва итүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Конкурс үткәрелү турындагы игъланда күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон рәвештә Конкурста катнашуга заявка бирә.

Конкурста катнашуга заявка, анда номинацияләрне, катнашучы турында белешмәләрне (физик зат өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик зат өчен – оешма исеме) һәм контакт мәгълүматын күрсәтеп, әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә бирелә. Әгәр Конкурс проекты авторлар төркеме тарафыннан әзерләнсә, Конкурста катнашуга заявкада барлык авторлар турында белешмәләр һәм аларның контакт мәгълүматы күрсәтелә. Юридик зат заявкасына оешма җитәкчесе тарафыннан имза салына һәм ул мөһер белән (булган

очракта) таныклана.

Заявкага Конкурс проекты (презентацияләр, статьялар, буклетлар һ.б.ш. өстәлеп) кушымта итеп бирелә. Конкурс проекты форматы, аның күләме, файдаланыла торган график һәм техник чаралар һәм алымнар дәгъва итүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән «Бюджет гражданнар өчен» проектын үстерү буенча эшче төркем рәисе, Россия Федерациясе финанс министры урынбасары А.М. Лавров тарафыннан 2016 елның 26 февралендә расланган конкурс йөкләмәләре нигезендә мөстәкыйль билгеләнә.

2.5. Конкурста заявкалары түбәндәге таләпләргә туры килә торган физик һәм юридик затлар катнаша:

заявкаларны вакытында бирү;

бер катнашучының бер генә заявка бирүе;

проектта номинацияләрне күрсәтү.

2.6. Заявкалар кабул итү тәмамланган көннән алып 5 (биш) эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы заявкаларны карый, аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен ачыклый һәм Конкурста катнашучыларның исемлеген төзи. Конкурста катнашучылар саны чикләнми.

Конкурста катнашуга алынмаган дәгъва итүчеләргә кире кагылу турында электрон почта аша заявкалар карау тәмамланган көннән алып 3 (өч) көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

2.7. Конкурска тәкъдим ителгән Конкурс проектлары, әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килми дип танылган заявкаларны да кертеп, катнашучыларга кире кайтарылмый.

## III. Конкурс үткәрү тәртибе һәм сроклары

3.1. Конкурс комиссиясе Конкурска тәкъдим ителгән Конкурс проектларын һәр номинация буенча төп һәм өстәмә критерийлар (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта) буенча бәяли.

Конкурс проектларына җыелма бәя Конкурс комиссиясенең барлык әгъзаларын бәяләү ярдәмендә барлыкка килә. Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы Конкурс проектларын һәр номинация буенча төп һәм өстәмә критерийларга туры килү мәсьәләсе буенча бәяли. Төп критерийга туры килү 10 (ун) – баллы, ә өстәмә –5 (биш) – баллы шкала буенча алга таба йомгаклау бәясенең суммар күрсәткечен исәпләү ярдәмендә бәяләнә.

Һәр номинациядә физик затлар һәм юридик затлар буенча аерым берәр җиңүче билгеләнә.

Конкурста берничә катнашучының баллары тигез булган очракта җиңүче ачык тавыш бирү юлы белән Конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә Конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Тавышлар тигез булганда, Конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була.

Конкурс проектларының җыелма бәясен исәпкә алып, Конкурс комиссиясе 2016 елның 8 августыннан да соңга калмыйча Конкурста җиңүчеләр турындагы беркетмәне раслый. Бу мәгълүмат 2016 елның 11 августыннан да соңга калмыйча,

Конкурста җиңүчеләрне һәм катнашучыларны бүләкләү тантанасының датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

3.2. Конкурс проектлары Конкурста җиңүчеләрнең ризалыгы белән 2016 елның 15 августыннан да соңга калмыйча федераль конкурсның икенче турында катнашу өчен Гражданнарга бюджет тәкъдим итү проектларының федераль конкурсын оештыручыга – «Россия Федерациясе Хөкүмәте каршында финанс университеты» федераль дәүләт югары белем бирү бюджет учреждениесенә тәкъдим ителә.

## IV. Дипломнар һәм сертификатлар

4.1. Конкурс нәтиҗәләре буенча:

4.1.1. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар тапшырыла.

4.1.2. Конкурста катнашучыларга катнашу турында сертификатлар тапшырыла.

## V. Мәгълүмат тарату

5.1. Конкурс турында, шул исәптән җиңүчеләр һәм катнашучылар хакында мәгълүмат Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

5.2. Конкурста җиңүчеләр һәм катнашучылар реклама-мәгълүмат материалларында, шул исәптән Интернет челтәрендә, катнашу һәм җиңү турында мәгълүмат урнаштырырга хокуклы.

5.3. Конкурста катнашуга заявкалар бирү Конкурста катнашучының Конкурс проектын бастырып чыгаруга, теләсә-нинди рәвештә күрсәтүгә, таратуга, гавами күрсәтүгә, шулай ук Интернет челтәрендә урнаштыруга ризалыгын белдерә.

Конкурста катнашучының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына үзенең Конкурс проектын бастырып чыгаруга, теләсә-нинди рәвештә күрсәтүгә, таратуга, гавами күрсәтүгә һәм Интернет челтәрендә урнаштыруга хокукы түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла.

5.4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Конкурс проектының эчтәлеге, Конкурста катнашучылар һәм җиңүчеләр турында, шул исәптән әлеге материалларны конференцияләрдә, семинарларда, түгәрәк өстәлләрдә һәм башка чараларда тарату максатларында, реклама-мәгълүмат басмаларын чыгарырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар бастырырга хокуклы.

Гражданнар өчен бюджет
тәкъдим итү проектларының
ачык гавами региональ конкурсын
үткәрү турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

**ГРАЖДАННАР ӨЧЕН БЮДЖЕТ ТӘКЪДИМ ИТҮ ПРОЕКТЛАРЫНЫҢ АЧЫК ГАВАМИ РЕГИОНАЛЬ КОНКУРСЫНДА КАТНАШУГА ЗАЯВКА**

| | |
|---|---|
| Катнашучының фамилиясе, исеме, ат.исеме* / оешма исеме | |
| Паспорт белешмәләре* / оешма реквизитлары организации | |
| Теркәлү адресы* / юридик адресы | |
| Контакт телефоны* | |
| Электрон почта* | |
| **Конкурс проекты тәкъдим ителгән номинация(ләр)нең исеме** | |
| Конкурс проекты исеме | |
| Кыскача аннотация (2-3 җөмлә) | |

Шәхси белешмәләр турында Россия Федерациясе законнары нигезендә үземнең шәхси белешмәләремне документаль һәм/яисә электрон рәвештә эшкәртүгә, файдалануга һәм таратуга ризалыгымны бирәм.

___________________ _________________________

имза* шәрехләү**

*Авторлар төркеме өчен һәркемнең белешмәләр бирүе мәҗбүри
** Оешмалар өчен – җитәкченең, вазыйфасын күрсәтеп, оешма мөһере белән таныкланган имзасы.

Гражданнар өчен бюджет
тәкъдим итү проектларының
ачык гавами региональ конкурсын
үткәрү турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Номинацияләр буенча конкурс биремнәренең эчтәлеге**

1.1. “Бюджет: күпме түлим һәм күпме алам?” номинациясендә күрсәтмә төп нөсхәдә түбәндәгеләр турында мәгълүмат тапшыруны күз алдында тота:

1) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына гражданнар башкарган түләүләрнең төрләре һәм уртача күләме;

2) бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә финанслана торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләре исемлеге һәм хакы;

3) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларыннан түләнә торган пособиеләрнең, пенсияләрнең, стипендияләрнең төрләре һәм күләмнәре;

4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә каплана торган халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтүләрнең төрләре һәм хакы.

Мәгълүмат 1 гражданны, гаиләне яисә аерым категория гражданнарын, гаиләләрен (яшь, тулы яисә тулы булмаган һ.б.ш.) күз алдында тотып тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта чираттагы финанс елына бюджетның план параметрлары буенча исәпләп чыгарылган белешмәләргә узган 2 – 3 елга ясалган динамик анализ йомгакларын да кертергә кирәк.

Биремне материал графика нигезендә күрсәтелгән мультимедиа презентациясе, видеофильм, интернет-брошюра, комикс рәвешендә эшләргә мөмкин.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең төп критерийлары: Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына гражданнар башкарган түләүләр турындагы һәм гражданнарга дәүләт (муниципаль) хезмәтләр күрсәтү, гражданнарга социаль ярдәм һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсенә караган чараларны финанслауга бәйле бюджет чыгымнары хакындагы мәгълүматның дөреслеге, тулылыгы һәм күрсәтмә материаллар белән тәэмин ителүе.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең өстәмә критерийлары:

- актуаль һәм аңлаешлы булу;
- күп мәгълүмат бирү;
- материалны эзлекле бәян итү;
- хатасыз язылу, әдәплелек;
- бизәлеш;
- үзенчәлек.

1.2. **“Муниципаль берәмлек бюджеты: сораулар һәм җаваплар” номинациясе** түбәндәгеләргә кагылышлы сорауларга җаваплар алырга мөмкинлек

бирә торган мәгълүматны кыска итеп, күрсәтмә материаллар кулланып, һәр граждан аңларлык итеп тапшыруны күз алдында тота:

- җирле бюджетлар керемнәренең составы, аларны туплау үзенчәлекләре, аларның динамикасына йогынты ясый торган факторлар;

- җирле бюджетлар чыгымнарының структурасы һәм динамикасы, гражданнарның уңайлы яшәү мохитен тәэмин итү һәм тормыш сыйфатын яхшырту, муниципаль берәмлектә эшкуарлык эшчәнлеген үстерү, муниципаль берәмлекләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү;

- җирле бюджет кытлыгының булу/булмавы, аны каплау чыганаклары, муниципаль бурыч динамикасы;

- җирле бюджетны төзү, раслау һәм үтәү тәртибе, гражданнарның әлеге процедураларда катлашу механизмнары.

Номинация халыкның киң катламын муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсешендә җирле бюджетларның роле, аларны формалаштыру үзенчәлекләре, гражданнарның муниципаль дәрәҗәдә бюджет процессында катнашу мөмкинлекләре белән таныштыру. Җаваплар конкрет муниципаль берәмлекнең яисә муниципаль берәмлекләр төркеменең бюджет планнары һәм факттагы параметрлары турында белешмәләр белән дәлилләнергә тиеш.

Бирем материалның, уку ярдәмлегенең, интернет-хрестоматиянең, мәгълүмат стендының график бирелеше белән, мультимедияле презентация рәвешендә башкарылырга мөмкин.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең төп критерие: муниципаль берәмлекләр бюджетларын төзүнең, муниципаль дәрәҗәдә бюджет процессын оештыруның төп мәсьәләләре буенча мәгълүматның төгәл һәм тулы булуы.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең өстәмә критерийлары:

- кыскалык;
- муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсешендә җирле бюджетларны тасвирлый торган мәгълүматның булуы;
- күрсәтерлек булу;
- хатасыз язылу, әдәплелек;
- бизәлеш;
- үзенчәлек.

**1.3. “Гражданнар өчен интерактив бюджет” номинациясе** халык белән үзара интерактив эшләүне тәэмин итүче заманча мәгълүмати технологияләрдән файдаланып бюджет турында мәгълүматны җыю, эшкәртү, күрсәтү һәм тарату процессларын тасвирлый торган проектларны бәяләү өчен билгеләнә.

Әлеге номинация буенча конкурс материаллары составында түбәндәгеләр тасвирланырга мөмкин:

- бюджет өлкәсендәге мәгълүмати-укыту программалары (проектлары, сервислары);
- гавами-хокукый берәмлек бюджеты (федераль, региональ яисә җирле бюджет) турында мәгълүмат табу һәм аны анализлау мөмкинлеген бирә торган эзләү программалары (проектлары, сервислары);

- гражданнар өчен бюджет әзерләүчеләр һәм мәгълүматтан файдаланучылар арасында “кире элемтә”не оештыру ысуллары (онлайн-консультацияләр, форумнар, социаль челтәрләр һәм башкалар).

Конкурс материаллары халык белән үзара интерактив эшләүне тәэмин итү максатында бюджет хакындагы мәгълүматтан файдалану мөмкин булган һәм күрсәтмә рәвештә тәкъдим итү өчен кулланыла торган интерфейс элементларын (виджетларны), апплетларны характерларга тиеш.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең төп критерие – конкурсант эшләгән (конкурсантның заказы буенча эшләнгән) электрон җайланмалар өчен интерактив кушымтаның булуы.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең өстәмә критерийлары түбәндәгеләр:

- җайланмаларның система таләпләренә җавап бирүе;
- файдалануы мөмкин булу;
- актуаль булу;
- аңлаешлы булуы;
- мәгълүматны визуальләштерү сыйфаты;
- үзенчәлек.

**1.4. “Гражданнар өчен бюджетның аңлаешлы булуы рейтингын эшләү” номинациясендә** проектның төрле максатчан төркемдәге гражданнар өчен аңлаешлы булуын бәяләү методологиясен һәм аңлаешлы булуы критерийларын (бәян итүнең аңлаешлы булуы, визуальләштерү, тәкъдим ителгән мәгълүматның аңлау өчен җитәрлек булуы) эшләргә тәкъдим ителә. Тәкъдим ителгән проектта проект авторлары фикеренчә бюджетның төрле максатчан төркемдәге гражданнар өчен аңлаешлы булуын ачып бирә торган сыйфатлы һәм (яисә) санлы күрсәткечләрнең исемлеге булырга тиеш.

Проект мультимедия презентациясе, график ярдәмендә күрсәтү, интернет-брошюра, газета мәкаләсе, мәгълүмати стенд рәвешендә булырга мөмкин.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең төп критерие – бюджетның төрле максатчан төркемдәге гражданнар өчен аңлаешлы булуын тәкъдим ителгән сыйфатлы һәм санлы индикаторлар ярдәмендә мөмкин кадәр ачып бирү.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең өстәмә критерийларына аңлаешлы булуның күрсәткечләренә карата куелган түбәндәге таләпләр керә:

- системалылык;
- креативлык;
- мәгълүматка бай булу;
- төрлелек;
- мәгълүматны визуальләштерү сыйфаты;
- оригинальлек.

**1.5. “Бюджет терминнарының популяр сүзлеге” номинациясендә** фәнни-популяр рәвештә бюджет законнары өлкәсендәге төшенчәләр турында мәгълүмат күрсәтергә тәкъдим ителә. Төшенчәләрне мисаллар һәм иллюстрацияләр ярдәмендә ачып бирү хуплана.

Проект интернет-брошюра, мультипликацион ролик, мультимедия презентациясе, видеофильм, фотоколлаж, китап басмасы һәм башкалар рәвешендә булырга мөмкин.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең төп критерие – терминны бәян итүнең эчтәлекле һәм аңлаешлы булуы, заманча фәнни алымнарга туры килүе.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең өстәмә критерийлары түбәндәгеләр:

- бюджет терминнарын колачлап алу киңлеге;
- мисаллар, иллюстрацияләр булу;
- креативлык;
- мәгълүматка бай булу;
- мәгълүматны визуальләштерү сыйфаты;
- оригинальлек.

**1.6. “Гражданнар өчен бюджетта социаль әһәмиятле проектлар” номинациясе** гавами-хокукый берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше өчен зур әһәмияткә ия булган, шул исәптән дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын кулланып гамәлгә ашырыла торган проектларны, мәсәлән, гомумрегиональ (муниципальара) характердагы объектларның капиталь төзелеше, күздә тота. Проектны социаль әһәмиятлегә кертүнең төп критерийлары түбәндәгеләр: проектны финанслауга җибәрелә торган бюджет чыгымнарының күләме зур булуы, проектның гомумрегиональ (муниципальара) характеры, шулай ук максатчан аудиторияне (социаль әһәмиятле проектны гамәлгә ашыру юнәлтелгән берничә максатчан төркем) киң колачлап алу.

Әлеге номинация буенча конкурс проектында социаль әһәмиятле проектларның гомуми характеристикасы, аларны финанслау күләмнәре, конкрет программа чаралары һәм аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре турында мәгълүмат булырга тиеш. Конкурс проекты интернет-брошюра, мультимедия презентациясе, видеофильм, график ярдәмендә күрсәтү рәвешендә булырга мөмкин.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең төп критерие – социаль әһәмиятле проект турында тәкъдим ителгән мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслеге.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең өстәмә критерийлары түбәндәгеләр:

- тәкъдим итүнең оригиналь булуы;
- яңалык, мәгълүматка бай булу;
- анализланган булу, хатасыз, әдәпле язылган булу;
- язу культурасы;
- конкурс биреме (номинация) асылының эчтәлегенә туры килүе;
- материалны бәян итүнең эзлеклелеге.

**1.7. “Инициатив бюджетлау проектлары” номинациясе** буенча конкурсның предметы инициатив бюджетлауның региональ программалары (Җирле инициативаларга ярдәм итү (ППМИ), партисипатор бюджетлау, “Халык бюджеты”, “Халык инициативасы” программалары һәм башкалар) кысаларында билгеле

муниципаль берәмлек территориясендә гамәлгә ашырылган проектларның социаль һәм икътисадый нәтиҗәләрен тасвирлаудан гыйбарәт.

Проектның тасвирламасында аның максаты, бурычлары, аны гамәлгә ашыру урыны, вакыты һәм механизмы, ирешелгән социаль нәтиҗәләр, гражданнар җыелышларында катнашучылар саны, җәмәгать файдаларын алучылар саны, халык, бизнес тарафыннан финанслашу күләмнәре турында белешмәләр һәм конкурсантлар фикеренчә әһәмиятле булган башка белешмәләр булырга тиеш.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең төп критерие – халыкның граждан инициативаларын гамәлгә ашыру барышында бюджеттан финанс белән тәэмин итү юлы белән ирешелгән социаль нәтиҗәләрне тасвирлау.

Әлеге номинация буенча конкурс проектын бәяләүнең өстәмә критерийлары түбәндәгеләр:

- мәгълүматка бай булу;
- мәгълүматны визуальләштерү сыйфаты;
- җәмәгать файдаларын алучылар саны;
- гражданнар җыелышларында катнашучылар саны;
- тәкъдим ителгән мәгълүматның дөреслеге;
- проектлардагы темаларның яңалыгы.